| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 30 мае** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1438** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 25 июлендәге 1557 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы «Инвалидлар хокуклары турында Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 26 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 25 июлендәге 1557 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү» хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.14 пунктында 2 нче баганага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз керүе, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул

исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла»;

2 бүлекнең 2.15 пунктында 2 баганауспны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның җитәрлек санда булуы;

мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

кануннарда каралган инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар булу.

Дәүләт хезмәт күрсәтүнең сыйфаты характерлана:

документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәгәндә;

муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу вакыты үтәлгәндә;

вазыйфаи затлар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин